ГЛАВА МАЙДАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МӘЙДАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_20.11.2020 с. Майдан № 3

## Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлегенең Тәмте урманчылыгы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябреннән 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» № 45-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Уставының 24 ст. нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлегенең Тәмте урманчылыгы авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020нчы елның 4нче декабренә билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"2021нче елда Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлегенең Тәмте урманчылыгы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерүгә килешәсезме?:

- урам яктырту идарәсе щитын сатып алу һәм урнаштыру;
- урамнарны яктырту лампалары сатып алу

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Халык җыенын Тәмте урманчылыгы авылы, Лесная урамы, 16нчы йорт адресы буенча урнашкан Урман кишәрлеге авыл клубы бинасы янында 09.30 сәгатьтә үткәрергә.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Мәйдан авыл җирлеге Башкарма комитеты билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Мәйдан авыл җирлеге башлыгы В. В. Михеев